**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ**
**КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25 октябрь 2022 **Чирмешән авылы** №362

**Чирмешән муниципаль районының**
**мәктәпкәчә белем бирү программаларын**
**гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында**
**караган һәм тәрбияләгән өчен**
**өлешчә мобилизация кысаларында**
**хәрби хезмәткә чакырылган**
**гражданнарның балаларын**
**түләүдән азат итү турында**

«Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияне игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарына ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» карары һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставы нигезендә Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Чирмешән муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләсендәге ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүдән азат итәргә (1 нче кушымта).
2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУга:

- 1 пунктта күрсәтелгән ташламаны Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация кысаларында мәгариф оешмасында тәрбияләнүченең ата-анасын (законлы вәкилен) хәрби хезмәткә чакыру турында хәрби комиссариат белешмәсе нигезендә бирергә;

- Россия Федерациясе Коралллы Көчләренә өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны кире кайтарган очракта, ташламаларның гамәлдә булу-булмавын тикшереп тору максатында хәрби комиссариат белән хезмәттәшлекне күздә тотарга.

3. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы Чирмешән муниципаль районының мәгариф оешмаларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләсендә тәрбияләнүчеләрне карап тотуны финанслауны тәэмин итәргә тиеш.

4. Бу карарның гамәлдә булуы 2022 елның 21 сентябреннән Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәт үтү вакытына килеп чыккан хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Р.Т. Айбатов

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның 25 октябрендәге
362 номерлы карары белән
расланды

**Чирмешән муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында караган һәм тәрбияләгән өчен түләүдән азат ителгән өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның балалары исемлеге**

| № | Баланың ФИАт.ис., туу датасы | Мәктәпкәчә гомуми белем бирү оешмасы исеме | Айга сумма (сум.) |
|---|---|---|---|
| 1. | Борисова Валерия Андреевна, 30.06.2019 | «Солнышко» Ивашкино балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 3375 |
| 2. | Галимова Ясминә Ирек кызы, 29.07.2018 | «Әмир башлангыч мәктәбе-балалар бакчасы» гомуми белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 1687 |
| 3. | Гыйләҗева Ясминә Ленар кызы, 16.08.2019 | "Ландыш" Чирмешән балалар бакчасы" мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 3382 |
| 4. | Мөгыйзов Айрат Ренат улы, 21.03.2016 | "Ландыш" Чирмешән балалар бакчасы" мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 3382 |
| 5. | Макарова Анна Андреевна, 18.10.2016 | "Каенкай" 2 нче номерлы Чирмешән балалар бакчасы" мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 3382 |
| 6. | Филиппов Даниил Виссарионович, 16.01.2019 | "Каенкай" 2 нче номерлы Чирмешән балалар бакчасы" мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 3382 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7. | Филиппова Ева Алексеевна, 08.09.2018 | "Ромашка" Күтәмә балалар бакчасы" мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 1687 |
| 8. | Александрова Ангелина Андреевна, 31.01.2017 | «Әкият» Чирмешән балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 3382 |